

Гадәттә, татар авыллары елга буена урнаша, я булмаса, якында күл була. Мордовиябездә дә шулай. Тирә-якны чиста тоту, табигатьне ярату кан белән сеңгән татар кешесенен. Мордовия халкы ел саен «Чиста яр» ботенроссия акциясендә актив катнаша. Җәй житте, сунын шифасын татыр очен, еш кына су буенда ял иткәндә vз-vзенне тәртипле алып барырга кирәк, ә алдан яр буен чистарту эшләре кон кадагына әйләнеп китте.      Су объектларынын яр буе тер- риторияләрендә, кешеләр кvпләп ял итә торган урыннарда, чvп-чар жыештыру чараларында, мәсәлән, Зубово-Поляна районында гына да педагогика коллияте, Зубово Поляна, Озёрная, Сосновка мәктәпләре, Сосновка һәм яна Потьма авыл жирлекләре администрациясе, УФСИН хезмәткәрләре белән бергә Кочетовка, Татар Лунданы, Горенка татар авыл халкы катнашты. «Зубово территориаль урманчылыгы» ГКУ хезмәткәрләре Каргашино авылы янындагы Печалово буасы ярын тәртипкә китерделәр. Ә кvпме татар авыллары Мокша елгасы буенда урнашкан?...Мәсәлән, Ельник районындагы татар авылларынын берничәсе: Акчеево-Кvгеш,Ваче- евка-Вачи һәм башкаларында да бу акциядә катнашучылар байтак. «Чиста яр - 2021» акциясендә катнашучыларнын, тату эше нәти-жәсе булып, су объектлары ярларында беренче тапкыр табигать яна тугандай булды.

«Чиста яр» акциясенен топ максаты - кешеләргә табигатькә болай битараф булмавын житкерv. Һәм беркем дә экологик проблемаларга битараф калырга тиеш тvгел. Безнен елгалар һәм кvлләр, яр буе территорияләре чиста, матур һәм ял итv очен унайлы булырга тиеш. Гаилә яки дуслар белән табигатькә чыгып, чираттагы пикниктан сон шешәләр һәм пластик савыт-саба чvплекләрен кvрәсе килми. Бәлки, кешеләр жыештырганнан сон монда ничек чиста булуын кvрерләр һәм чvп-чар ташламаслар. Барыбызнын да жирне матур итеп кvрәсе килә. Бу эшкә vз олешебезне кертергә кочебез бар: һәрберебез vз артыннан жыештырудан башларга гына кирәк.

Н.ХӘЛИЛ